| | | |
|---|---|---|
| РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН<br>**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ НУРЛАТСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА** | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>**НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ** |

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

26.06.2019 № 556

**Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының 2018 елның 27 августында кабул ителгән 673 нче карарына үзгәрешләр кертү турында**

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы яшьләр сәясәте дәүләт оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турында» 2018 ел, 14 август, 665 нче карары белән расланган «Яшьләр сәясәте дәүләт оешмалары һәм Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгы ведомствосындагы аерым типлаштырылмаган оешмалар хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 елның 21 июнендәге 505 номерлы карары нигезендә

КАРАР БИРӘМ:

1. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы яшьләр сәясәте муниципаль оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турында» 2018 елның 27 августындагы 673 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты карамагындагы аерым типлаштырылмаган оешмалар һәм яшьләр сәясәте дәүләт оешмалары хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

V кисәктә:

2.4 пунктның алтынчы абзацында «26,5» санын «41,0» санына алыштырырга;

6 нчы таблицаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6нчы таблица

Хезмәт интенсивлыгы өчен өстәмә түләүләр күләме

| Һөнәри квалификация төркеменең исеме | Квалификация дәрәҗәсе | Өстәмә күләме, процент |
|---|---|---|
| Беренче дәрәҗәдәге укыту-ярдәмче персонал хезмәткәрләре вазыйфаларының һөнәри квалификация төркеме | | 41,0 |
| Икенче дәрәҗәдәге укыту-ярдәмче персонал хезмәткәрләре вазыйфаларының һөнәри квалификация төркеме | беренче | 41,0 |

| | | |
|---|---|---|
| Педагогик хезмәткәрләр вазыйфаларының һөнәри квалификация | Беренче-дүртенче | 41,0 |
| Профессиональ квалификация төркеме | беренче | 46,0 |
| | икенче | 49,0»; |

4.4 пунктның алтынчы абзацында «26,5» санын «41,0» санына алыштырырга;

11 нчы таблицаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«11нче таблица

Хезмәт интенсивлыгы өчен өстәмә түләүләр күләме

| Һөнәри квалификация төркеменең исеме | Вазыйфаның исеме | Өстәмә күләме, процент |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| «Ярдәмче составның техник башкаручылары һәм артистлары вазифалары» | Барлык вазыйфалар | 41,0 |
| “Урта звено мәдәният, сәнгать һәм кинематография хезмәткәрләре вазыйфалары” һөнәри квалификация төркеме | аккомпаниатор, костюмнар бүлеге мөдире | 49,0 |
| | түгәрәк, һәвәскәрләр берләшмәсе, кызыксынулар клубы җитәкчесе, культорганизатор | 61,0 |
| 1 | 2 | 3 |
| “Әйдәп баручы звеноның мәдәният, сәнгать һәм кинематография хезмәткәрләре вазыйфалары” һөнәри квалификация төркеме | Барлык вазыйфалар | 49,0 |
| «Мәдәният, сәнгать һәм кинематография учреждениеләренең җитәкче составы вазыйфасы» һөнәри квалификация төркеме | Барлык вазыйфалар | 49,0»; |

8 пунктның бишенче абзацында 8 бүлектә «10» санын «20» санына алыштырырга».

2. Әлеге карарның гамәлдә булуы 2019 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга.

Җитәкче вазыйфаларын
башкаручы Р.Р. Шәмсетдинов